ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 200, с.Качелино ,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМЕТЕТЫ
Үзәк урам, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93 E-mail: Kach.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 12 » май 2025 ел № 34

**Кәче авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 13 декабрендәге “Яңа ел бәйрәме чараларын үткәрүгә әзерлек һәм бәйрәмнәр вакытында янгын куркынычсызыгын тәэмин итү турында” 26 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

РФ Хөкүмәтенең 2015 елның 28 августындагы “Россия Федерациясе һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасы турында” 901 номерлы карары, РФ Хөкүмәтенең 2010 елның 11 мартындагы “Россия Федерациясе һава киңлегеннән файдалануның Федераль кагыйдәләрен раслау турында” 138 номерлы карары (29.03.2024 редакциясе), РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары белән расланган РФдә янгынга каршы режим кагыйдәләре нигезендә, Арча муниципаль районының Кәче авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кәче авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 13 декабрендәге “Яңа ел бәйрәме чараларын үткәрүгә әзерлек һәм бәйрәмнәр вакытында янгын куркынычсызыгын тәэмин итү турында” 26 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктына түбәндәге абзац өстәргә:

«Биеклеге 50 метрдан артыграк булган салютлар һәм фейерверклар үткәргәндә, шулай ук җир яисә су өслегенә һава юллары полосаларын проекцияләү чикләрендә салютлар һәм фейерверклар биеклегенә бәйсез рәвештә һава пространствосыннан файдалану Россия Федерациясе һава хәрәкәтен оештыруның Бердәм системасы оператив органы (алга таба - Вәкаләтле орган) рөхсәте белән гамәлгә ашырыла.

Фейерверк уздыру өчен вәкаләтле органнан рөхсәт алырга кирәк. Язма рөхсәттән башка муниципаль берәмлек территориясендә фейерверк уздыру тыела.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Арча муниципаль районының рәсми сайтында arsk.tatarstan.ru “Җирлекләр” бүлегендә бастырып чыгарырга, махсус мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан, түбәндәге адреслар буенча халыкка җиткерергә: Кәче авылы, Үзәк ур., 200 йорт; Чулпан авылы, Гагарин урамы, 7а йорт; Якты Көн авылы, Якты ур., 30а йорт.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Кәче авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р. Р. Гәрәев